| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь г.Казань № 1660

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планын раслау турында» 2022 ел, 22 декабрь, 1390 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планын раслау турында» 2022 ел, 22 декабрь, 1390 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 август, 967 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2022 – 2030 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең экологик үсеше һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-техник эшчәнлекне гамәлгә ашыру планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

2 нче графада «Гамәлгә ашыру» сүзләреннән соң «Дәүләт» сүзен өстәргә, «2013 - 2023 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 графада «2023» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

3.2 пунктның 3 графасында «2025» саннарын «2030» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «3.3. | «Углерод эзе һәм климат проектлары сертификациясе һәм хисапларын валидацияләү» квалификация күтәрү | 2023 – 2030 еллар»; |

| | | |
|---|---|---|
| | программасы буенча кадрларны укыту һәм әзерләү (килешү буенча) | |

4.1 пунктның 3 графасында «2025» саннарын «2030» саннарына алмаштырырга;
5.1 пунктның 3 графасында «2025» саннарын «2030» саннарына алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле 6 - 8 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «6. | «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе | |
| 6.1. | Экологик үсеш һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен башкару (килешү буенча) | 2023 – 2030 еллар |
| 7. | «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе | |
| 7.1. | Экологик үсеш һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен башкару (килешү буенча) | 2023 – 2030 еллар |
| 7.2. | «35.04.04 Агрономия» юнәлеше буенча кадрлар укыту һәм әзерләү (килешү буенча) | 2023 – 2030 еллар |
| 8. | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе | |
| 8.1. | Экологик үсеш һәм климат үзгәрешләре өлкәсендә фундаменталь һәм гамәли фәнни эшләр башкару (килешү буенча) | 2023 – 2030 еллар». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин